БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_01_» _07_ 2019 г. № _246_

**Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 15 сентябрендәге 301 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы дәүләт яки муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыны белән файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158, статья нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүдән баш тарткан һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр башкарудан баш тарткан очракта, торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында" 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән", Россия Төзелеш Министрлыгының "Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыны белән файдаланган өчен түләү билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында" 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгы белән Балтач район башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 15 сентябрендәге 301 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондыннан торак урыннары найм шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыны белән файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацындагы «муниципаль берәмлектә» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 пунктның 6 абзацындагы «муниципаль берәмлектә» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов